**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская,
дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 май 2023 № 397

**Әтнә муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл яны полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең Җир кодексына, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына, “Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүлеп бирү полосалары һәм юл яны полосалары турында” 2008 елның 1 декабрендәге 841 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына ярашлы, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыру, Әтнә муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдалануны контрольдә тотуны тәэмин итү максатларында **карар итәм:**

1. Әтнә муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүлеп бирү полосаларын һәм юл яны полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф.Каюмов